| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 29 декабрь № 1001

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 12 февраль, 38 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 12 февраль, 38 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 27 июнь, 515 нче; 2012 ел, 9 февраль, 93 нче; 2012 ел, 31 август, 746 нчы; 2013 ел, 14 март, 160 нчы; 2013 ел, 29 август, 611 нче; 2014 ел, 28 март, 194 нче; 2014 ел, 7 июнь, 388 нче; 2014 ел, 30 август, 630нчы; 2015 ел, 21 октябрь, 789 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.3 нче пунктта:

3.3.1 нче пунктчага түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«урман фонды җирләре составындагы урман участокларына мөнәсәбәтле урман участокларының проект документларын раслау.»;

түбәндәге эчтәлекле $3.3.1^1$ нче пунктча өстәргә:

«Урман мөнәсәбәтләре өлкәсендә (федераль милектә булган урман фонды) Татарстан Республикасы вәкаләтләре:

урман-парк зоналарында булган зоналарны, урман-парк зоналары, яшел зоналар мәйданын билгеләү, урман-парк зоналары, яшел зоналар чикләрен билгеләү һәм үзгәртү буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тәкъдимнәр кертә;

Россия Федерациясе Урман кодексының $29^1$ статьясындагы 4 өлеше нигезендә кече һәм урта эшкуарлык субъектлары белән төзелә торган урман утырмаларын

сату-алу шартнамәсе буенча түләүне хисаплаганда кулланыла торган, урманнарны саклау, яклау, булдыру чараларын үткәрүне тәэмин итүгә чыгымнарны билгеләү өчен коэффициентны билгели.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\1001.docx